| | |
|---|---|
| Республика Татарстан<br>САБИНСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ ГОРОДСКОЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | Татарстан Республикасы<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«22» января 2026 года № 7

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Саба шәһәр җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урыннарын булдыру турында

РФ Хөкүмәтенең "Яктырту жайланмаларын, электр лампаларын тиешенчә жыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, урыннан-урынга күчерү һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә һәм сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохитка зыян китереүе мөмкин булган өлешендә, җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында" 28.12.2020 елгы №2314 карарының 5 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге территориясендә терекемешле лампаларны туплау урыннары булдырырга, шул исәптән мондый туплау урыннарын оештыру күпфатирлы йортларда туплау урыннарын оештыру өчен урыннар булмау сәбәпле мөмкин булмаган очракларда, түбәндәге адрес буенча:

422060, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, ш.т.б. Байлар Сабасы, Заводская ур., 19 йорт ЖЧЖ «Сабэнергосервис» хакимияте бинасы,

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Саба шәһәр җирлеге территориясендә терекөмешле лампаларның туплану урыннары урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, шулай ук мәгълүматны җирлекнең рәсми сайтында, түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә:

- 422060, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, ш.т.б. Байлар Сабасы, Школьная ур., 31 а йорт Саба шәһәр җирлеге хакимияте бинасы;

- 422060, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Урта Саба авылы, Г. Тукая ур., 33 йорт мәдәният йорты бинасы.

3. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр башкарма комитетының «Терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннарын раслау турында» 12.02.2014 елгы № 19 карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге рәсми сайтында https://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча урнаштырырга., шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган мәгълүмат стендларында:

- 422060, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, ш.т.б. Байлар Сабасы, Школьная ур., 31 а йорт Саба шәһәр җирлеге хакимияте бинасы;
- 422060, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Урта Саба авылы, Г. Тукая ур., 33 йорт мәдәният йорты бинасы.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Саба шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Р.Г. Гыйлманов